Частное общеобразовательное учреждение «Татнефть-школа»

| | | |
|---|---|---|
| Рассмотрена и принята<br>на педагогическом совете<br>Протокол № 1<br>«29» 08 2019 г. | Согласована<br>Зам. директора по УВР<br>ЧОУ «Татнефть-школа»<br>_______ Н.А.Шокурова<br>«29» 08 2019 г. | Утверждаю<br>Директор<br>ЧОУ «Татнефть-школа»<br>_______ О.А.Калягина<br>Приказ № ___<br>«___» ______ 2019 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

## учебного предмета «Родной язык»

## для 1-4 класса (татарская группа)

**Сафина Гульназ Исмагиловна**
Учитель татарского языка

2019 – 2020 учебный год

**<u>Частное общеобразовательное учреждение</u>**

## Аңлатма язуы

## Укыту предметының гомуми аңлатмасы

Татар телен дәүләт теле буларак укыту – аралашу чарасы, шулай ук укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү, аларның аралашу культурасын формалаштыру ысулы да. Татар телен аралашу чарасы буларак үзләштерү нәтиҗәсендә укучылар көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләренә ия булалар.

Татар теле, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә хезмәт итә, шулай ук укучыларны татар халкының мәдәнияте һәм милли үзенчәлекләренә якынайта, толерантлык, мәдәниятара аралашу осталыгы кебек универсаль күнекмәләр булдыруга этәргеч ясый.

## Башлангыч мәктәптә татар теле укытуның максатлары:

1. Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш уяту, үз милләтеңә һәм аның теленә мәхәббәт хисләре тәрбияләү.
2. Балаларда татар теленең барлык тармаклары буенча мәгълуматлылыкны (компетенцияне) булдыру.
3. Укучыларда аралашу өлкәсенә караган мәгълуматлылыкны булдыру. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча аралашканда, тел чараларыннан урынлы файдаланырга өйрәтү.
4. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру. Укучыларда татар мәдәниятына караган мәгълуматлылыкны үстерү.

## Укыту предметының укыту планында тоткан урыны

Татар телен укытуга 1 нче сыйныфта 34 сәг., 2 нче сыйныфта 68 сәг., 3 нче сыйныфта 68 сәг., 4 нче сыйныфта 34 сәг бирелә. Дәресләр атнага 1 сәгать исәбеннән 1, 4 нче сыйныфларында, 2 сәгать 3, 4 сыйныфта каралган.

## Предмет нәтиҗәләрен контрольгә алу формалары һәм төрләре, аларның саны

Предмет нәтиҗәләрен контрольгә алу контроль эшләр, контроль диктантлар, контроль күчереп язу, сүзлек диктантлары аша тикшерелә.

1 нче сыйныфта билгеләр куелмый (Россия Федерациясенең гомуми һәм профессиональ белем бирү министрлыгы хатына (25.09.2000 №2021/11-13) нигезләнеп).

## Предмет нәтиҗәләрен контрольгә алу чараларының саны

| **сыйныфлар** | **контр. эшләр** |
|---|---|
| 1 | 1 |
| 2 | 5 |
| 3 | 5 |
| 4 | 5 |

Арадаш аттестация нәтиҗәсе булып 4 чиреккә куелган барлык билгеләрнең (фән буенча үткәрелгән агымдагы барлык контроль эшләрнең) уртача баллы санала. 1 нче сыйныфта арадаш аттестация аерым үткәрелә.

Эшләрне бәяләү программа авторларының бәяләү нормаларына, “2015/2016 нчы уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре” методик тәкъдимнәренә һәм Хосусый гомуми белем бирү оешмасы “№23 “Менеджер” урта гомуми белем бирү мәктәбе” укучыларының белем алу нәтиҗәләрен бәяләү системасы турындагы нигезләмәгә таянып үткәрелә.

**Укыту предметының шәхси, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләре**

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре**

Гомуми белем бирү мәктәбен тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнәтирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана:**

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру, телнең матурлыгын һәм сәнгатьлеген тою, татар телен өйрәнүгә карата кызыксыну уяту;
- үзеңнең һәм башкаларның хис-тойгыларын тоемлау, әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау, әйткән һәм язган сүзләрең өчен җаваплылык тоемлау;
- текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү
- “Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, “башкаларга карата түземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү;
- туган республикага, гаиләгә, туганнарга карата хөрмәт, әти-әнине ярату; үз милләтеңне ярату, татар булуың белән горурлану;
- укуга һәм белем алуга уңай мотив формалаштыру, аңа карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү,
- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләрен һәм геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү; эш-гамәлләрне бәяләү;
- язма сөйләмгә карата кызыксыну, сөйләм телен үстерүгә омтылу;

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Татар теле укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен **(танып белү, регулятив, коммуникатив)** формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни, төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә; укучыларда, компьютер яисә ИКТнең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**

- дәреслек белән эш итә белү.

- хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку.
- этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку.
- текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсенә төшенү.
- текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.
- укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.
- предметларны, чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү.
- укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген сөйли белү.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

- уку хезмәтен планлаштырырга өйрәтү;
- үзенә максат куярга өйрәтү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;
- укудагы уңышлылыгын һәм уңышсызлыкларын күрә белү;
- укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
- уку хезмәтенә бәя бирә белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли белү, алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү;

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү
- укытучының, классташларның сорауларына җавап бирү;
- сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү.
- башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.
- парларда, төркемнәрдә эшли белү.
- “Телдән әзерлек чоры” өчен тәкъдим ителгән темалар буенча бирелгән сүзләрне монологик һәм кара – каршы сөйләмдә куллана белү;
- хәрефләрдән иҗекләр, иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмә һәм билгеле бер ситуацияләргә карата җөмләләр төзү;
- татар теленең үзечәлекле авазларын дөрес уку, аларны язуда күрсәтү;

**Укытуның предмет нәтиҗәләре**

Туган телгә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру; үз халкыңның, Россия һәм дөнья мәдәниятының бердәмлеге һәм күпкырлылыгы турында башлангыч күзаллау формалаштыру; сөйләм эшчәнлеге төрләрен (тыңлап аңлау, уку, сөйләм һәм язу) камилләштерү; шәхеснең интеллектуаль һәм иҗади сәләтен үстерүдә телнең алыштыргысыз ролен аңлау; туган телнең коммуникатив, танып-белү,гамәли мөмкинлекләрен куллану; туган тел турында башлангыч белемнәрне формалаштыру һәм системага салу; аның дәрәҗәсе һәм берәмлекләренең үзара бәйләнештә торуын аңлау; туган телнең төп берәмлекләрен һәм грамматик категорияләрен үзләштерү; актив һәм потенциаль

сүзлек запасын баету, сөйләм этикеты нормаларын үзләштерү; телдән һәм язма гыйбәрәләрдә аларны куллану тәҗрибәсен булдыру; гомумкешелек кыйммәте буларак тел мәдәнияты өчен җаваплылык формалаштыру.

**Тыңлап аңлау**

Укытучының (сыйныфташыңның) өйрәнгән материалга нигезләнгән сөйләмен тыңлап аңлау.

Текстны тыңлаганнан соң, төп фикерне аера белү.

Татарча сөйләмне тыңлап, сүз һәм җөмлә чикләрен билгеләү.

Текстны тыңлап аңлагач, аңа исем бирү.

Ишеткән өйләмнең, җөмләнең эчтәлегенә төшенү.

**Сөйләү**

Укытучы тәкъдим иткән, программада каралган темалар буенча әңгәмә кору.

Диалогта катнашу.

Текстның эчтәлеген үзгәртмичә сөйләү.

Рәсем яки план нигезендә сөйләү.

Укыганның эчтәлеген сораулар нигезендә сөйләү.

Татар теленә хас булган эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзәрен куллану.

**Уку**

Текстны (хикәя, шигырь, әкият) татарча сәнгатьле итеп уку.

Балалар өчен нәшер ителгән китаплар, газета-журналларны, әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес, йөгерек һәм аңлап уку.

Укыган текстның төп фикерен аңлатып бирү.

Этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны аңлап уку.

Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсенә төшенү.

Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.

**Язу**

Бирелгән темага сочинение язу.

Орфографик күнегүләрдән соң тыныш билгеләре булган диктантлар язу.

План нигезендә изложение язу.

Мәктәп, гаилә, үзең турында кечкенә хикәяләр яки котлау кәгазьләре язу.

**Укучыларда МКТ компетенциясе формалаштыру**

МКТ куллану балаларга белем бирү эшчәнлеген җанландырып җибәрә, эмоциональ яктан балаларга уңай тәэсир итә. Балалар күрсәтмә материалны җиңел кабул итә, аларда кызыксыну уята. Материалларның сыйфатына килгәндә, алар тәэсирле, матур, зур.

Диагностика нәтиҗәләре шуны күрсәтә: балаларның танып белү һәм фикерләү өлкәсендәге үсеш дәрәҗәсе югары. Элекке вакытта үсеш дәрәҗәсе буенча беренче урында физик һәм сәнгать өлкәсе тора иде. МКТ куллануның нәтиҗәлелеге шунда: без алда әйтелгән өлкәләрдә сикереш ясадык. Бу бик мөһим. МКТ психологик яктан мәгълүматны кабул итүне җиңеләйтә. Балаларга экрандагы образлар бик якын, таныш һәм кызык. Эшчәнлек барышында алар хәтта яңа белем, күнекмәләр алуын сизмичә дә калалар.

МКТ куллану гомуми белем дәрәҗәсен киңәйтә. Яңа технологияләр, алымнар, чаралар – замана таләбе. Шуларны эшчәнлектә файдаланып, без

балаларны алдагы мәгълүмати дөньяга әзерлибез. Күрсәтмә материаллар куллану дәрәҗәсе үсә, мөмкинлекләр арта: рәсемнәр, презентацияләр, видеоязмалар, аудиоязмалар һ.б. кулланырга мөмкин.

Тәрбияче һәм балаларның хезмәт җитештерүчәнлеген арттыра. Моның өчен МКТ барлык шартларны тудыра: акыт экономияләнә һәм дәреснең нәтиҗәлелеге арта. МКТ күп мәгълүматны кыска формада, гади һәм җиңел кабул итәргә мөмкинлек бирә.

Белем бирү процессы эчтәлеге индивидуаль шәхескә ориентлаша. Һәрбер баланың күрү, ишетү органнары активлаша, фикерләү сәләте үстерелә.

**МКТ чаралары белән танышу, компьютер белән эшләгәндә гигиена**

**Укучы өйрәнәчәк:**

• компьютер һәм МКТ чаралары белән эшләгәндә күз, нерв системасы, терәк-хәрәкәт аппараты органнарына зыяны булмаган алымнар кулланырга;

• компьютерда шәхси мәгълүматлар саклау өчен папкалар системасы оештырырга.

**Компьютерга мәгълүмат кертү технологиясе: текст язу, тавыш, рәсем яздыру**

**Укучы өйрәнәчәк:**

• төрле техник чаралардан (фото - видеокамерадан, микрофоннан һ.б.ш.) компьтерга мәгълүмат кертергә;

• татар телендә текст яза белергә; аерым сүзләрне тәрҗемә экранында кулланырга;

• график планшетта рәсемнәр ясарга;

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

сканер аша үткән татар текстын таный торган программаны кулланырга.

**Мәгълүмат эзләү һәм эшкәртү**

**Укучы өйрәнәчәк:**

• мәгълүмат чыганаклары турында сөйләргә;

• өстәмә компьютер җайланмаларын кулланырга; (принтер, сканер, модем, цифрлы фотоаппарат, цифрлы видеокамера, видеопроектор, тавыш колонкалары);

• компьютерда эшләгәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәргә;

• дисковод һәм электрон диск белән эшләргә;

• текст һәм сурәтләр белән эшләргә;

•клавиатура белән эшләгәндә санитар-гигиена кагыйдәләрен үтәргә.

**Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

• үз регионыңның хезмәт династиясе традицияләрен бәяләргә;

• проект эшчәнлеге: информация җыю, яхшы вариантны сайлау, эшләнмәне сынап карарга;

• төрле мәгълүмат чыганакларын кулланып, кирәкле мәгълүматны табарга.

**Аңлап уку һәм текст белән эшләү стратегияләре**

Аралашуга юнәлтелгән укытуны тормышка ашыруда текстка таяну мөһим шарт булып тора.

Текстоцентрик укытуга теоретик дәлил Е.А. Быстрова, К.З. Закирьянов, Н.А. Ипполитова, В; И. Капинос, Г.В. Колшанский, М.Р. Львов, Н.В. Львов, Г.М. Пахнова, Р.Б. Сабаткоев һәм башка авторларның эшендә чагылыш тапкан.

Текстны сөйләп бирү укучыларга сөйләм теленә төшенергә ярдәм итә, һәм үзлектән аңлы рәвештә сөйләм сәләтен арттыра. Укучыларда тел тоемлавы формалаштыруга булышучы үрнәк сөйләм теле тирәлеге булдыру аралашу компетенциясен үстерү өчен иң мөһим шартларның берсе булып, тора. Шул ук вакытта аларда рухи-әхлакый һәм эстетик үсеш тәрбияләү дә булырга тиеш. Бу шартны тормышка ашыру максаты белән дәрескә уңышлы текстлар сайлап ала белү бик мөһим.

Мәктәптә татар телен өйрәнүдә текстларның әһәмияте гаять зур. Текст актив лексиканы сөйләм телендә куллануга мөмкинлек тудыра. Хәзерге вакытта мәктәпләрдә “текст” төшенчәсе киң кулланыла. Ләкин текст барлык таләпләргә туры килергә – эзлекле, тәмамланган, билгеле бер мәгънәгә ия, лексик һәм текстта грамматик яктан төгәл булырга тиеш. Укучылар үз чиратында алмашлыкларны грамматик категория буларак белергә һәм сөйләмдә кулланырга тиеш.

Тәҗрибә күрсәтүенчә, укучыларда үз фикерләрен әйтеп бирә алу сәләтен нәтиҗәле һәм эзлекле итеп үстерүдә үрнәк текстларны анализлау ярдәм итә, текстны бер төрдән (сөйләп бирү) икенче төргә (инша язу) күчерү күнекмәләрен арттыра.

**Текст белән эш: мәгълүмат эзләү һәм укыганны аңлау**

**Укучы өйрәнәчәк:**

• тексттан төгәл белешмәләр,фактлар табарга;

• текстның темасын һәм төп мәгънәсен ачыкларга;

• текстны мәгънәви кисәкләргә бүләргә, текстның планын төзергә;

• тексттагы төп вакыйгаларны аерып чыгарырга һәм аларның эзлеклелеген билгеләргә;

• төрле чара ярдәмендә бирелгән мәгълүматны (телдән, таблица, схема, диаграмма) аңларга;

• текстны андагы мәгълүматка карап кына түгел, ә жанр, төзелеше, сурәтләү чараларыннан чыгып аңларга;

• укуның төрле төрләренә (танышу, өйрәнү, эзләнү) мөрәҗәгать итәргә;

• яшь үзенчәлекләренә туры килгән сүзлекләр һәм белешмәләрдән файдаланырга.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

• кирәкле мәгълүмат эзләү өчен, тектсның формаль элементларын (бүлекчәләр, сноскалар) кулланырга; берничә мәгълүмат чыганагы белән эшләргә;берничә чыганактан алынган мәгълүматны чагыштырырга.

**Текст белән эш: үзгәртү һәм мәгълүматны интерпретацияләү**

**Укучы өйрәнәчәк:**

• текстның эчтәлеген тулысынча һәм кыскача, телдән һәм язма рәвештә сөйләргә;

• текстның гомуми идеясе белән фактларны аерырга;

• текстка таянып нәтиҗәләр чыгарырга; аларны раслый торган фактлар табарга;

• тектсның төрле өлешендәге мәгълүматны чагыштырырга һәм гомумиләштерергә;

• куелган сорауга җавап итеп, текстка нигезләнеп кыскача монологик сөйләм төзергә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

• алга таба да кулланыр өчен, укылган тексттан өземтәләр ясарга;

• текстка кыскача бәямәләр язарга.

**Текст белән эш: мәгълүматны бәяләү**

**Укучы өйрәнәчәк:**

• укылган текст буенча бәяләү характерындагы фикерләрен җиткерергә;

• текстның эчтәлеген, тел үзенчәлекләрен һәм төзелешен бәяләргә; иллюстратив рәтнең урынын һәм ролен билгеләргә;

• укылган яки тыңланган текст турында фикер алышуда катнашырга.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

• төрле карашларны чагыштырырга;

• автор фикере белән үзенекен туры китерергә;

• бер яки берничә чыганак белән эшләгәндә төгәл (капма-каршы) мәгълүматны күрсәтергә.

**Курсның эчтәлеге**

“Танышу”, “Безнең мәктәп”, “Безнең гаилә”, “Ашамлыклар”, “Кеше”, “Өс-баш һәм аяк киемнәре”, “Уеннар”, “Авылда”, “ Шәһәрдә”, “Кошлар”, “ Бәйрәмнәр” темалары буенча сүзлек белән танышу һәм аларны сөйләмдә куллану.

Җөмләләрнең мәгънәләрен аңлап, Син кем? Исемең ничек? Ул кем? Ул Саматмы? Бу кем? Аның исеме ничек? Сиңа ничә яшь? Кебек сорауларга җавап бирү.Әйе, юк, түгел сүзләре белән раслау һәм инкяр җөмләләр төзү тәрбияләү.Зат алмашлыкларын кулланып, предметның кемгә караганлыгын белдерү.

Кем? Нәрсә? Бу нәрсә? Кемнең? сораулары.Предметның барлыгы, юклыгы.Нинди? Ничә? Кая? Кайда? Нишли? Нәрсә укый? Нәрсә белән? Ничек? Кайсы? сораулары. Саннар һәм ким җөмләләр.

Бар, юк сүзләре.

Дөрес язу һәм сөйләү күнекмәләре булдыру.Иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес итеп әйтү һәм язу. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан – юлга күчерү. Калын һәм нечкә сузыкларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Алфавит. Сузык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар. Сингармонизм законы.

Татар телендәге исем, фигыль, сыйфат, сан сүз төркемнәре белән таныштыру. Исем, аның мәгънәсе, сораулары, берлек һәм күплек сан формалары, килеш белән төрләнүе; фигыль, аның мәгънәсе, сораулары, заман формалары, сыйфат, аның мәгънәсе, сораулары, сыйфатларның сыйфатланмышы, синоним, антоним сыйфатлар; сан, аның мәгънәсе, сораулары. Саннарны сөйләмдә дөрес куллану. Татар телендә сан белән саналмышның бәйләнеш үзенчәлекләре. Аергыч турында мәгълүмат бирү.

Алмашлыклар. Зат алмашлыклары. Аларның мәгънәләре, килеш белән төрләнеше. Сорау алмашлыклары турында мәгълүмат бирү. Төрле интонация белән әйтелгән җөмләләрдән соң куелган тыныш билгеләр. Бирелгән тексттан сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес итеп күчереп язу. Матур язу күнегүләре.

Җөмләнең баш кисәкләре турында мәгълүмат бирү, аларның урнашу тәртибен күзәтү, аны рус теле белән чагыштыру; бирелгән сүзләр һәм сүзтезмәләр белән җөмләләр төзү. Тәрҗемә күнекмәләре булдыру.

Укытучының (иптәшеңнең) сорауларын аңлап, гади җөмләләр белән җавап бирү. Укылган өзекнең төп фикерен үз сүзләрең белән әйтү. Темаларны өйрәнү вакытында аңлатмалы һәм сүзлек диктантлары язу. Аерым рәсемнәр һәм әйберләрне сурәтләп биргәндә, исем, сыйфат, фигыльләрне дөрес куллану.

Тизәйткеч, санамыш, табышмак, мәкаль-әйтемнәрне ятлау.

Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Күп мәгънәле сүзләр. Синоним, омоним, антоним сүзләр. Сүзлекләр турында мәгълүмат бирү. Аларны тексттан табу, сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллана белү. Сүзлекләр турында мәгълүмат бирү һәм алар белән эшләргә өйрәтү

Тамыр һәм кушымча.Тамырдаш сүзләр. Тамыр һәм ясалма сүзләр.Татар һәм рус телләрендә сүзләргә кушымчаларның ялгану тәртибе һәм үзенчәлекләре. Кушма һәм парлы сүзләр.

Җөмләнең коммуникатив төрләре: раслау, сорау, өндәү һәм инкяр җөмләләр. Алар янында тыныш билгеләре. Инкяр итүнең төп формалары: хәбәр булып килгән фигыльдә юклык кушымчаларын, түгел кисәкчәсен, юк хәбәрлек сүзен куллану. Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләдә сүз тәртибе. Русча җөмләләрне татарчага тәрҗемә итү. Татар телендә җөмләдә сүз тәртибе (ия белән хәбәрнең, аергыч белән аерылмышның урыннары). Бирелгән тема буенча диалог төзү, монологик сөйләм оештыру. Башланган диалогны яки монологны дәвам итү (төгәлләү).

**Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре**
**«Фонетика , графика , орфоэпия » бүлеге**

**Укучы өйрәнәчәк:**

• аваз һәм хәрефләрне аера белергә;
• татар авазларына характеристика бирергә (нечкә/калын, парлы/парсыз, саңгырау/яңгырау тартыклар); аларга бәйле төп фонетик законнар (сингармонизм, ирен гармониясе турында) төшенчә бирергә;
• сүзләрне тәртипкә салу һәм кирәкле мәгълүмат табу өчен алфавит белән кулланырга.

**Укучы мөмкинлек алачак:**

• авазларны дөрес әйтү нормаларын истә тотып, барлык татар авазларын ишетеп аңларга һәм әйтергә;
• сүздә, фразада басымны дөрес куярга;
• сүзләргә фонетик-график анализ (аваз-хәреф анализы)ясарга; үрнәк буенча сүзләрне тикшерә һәм тикшерүнең дөреслеген исбатларга.

**«Сүз» бүлеге**

**Укучы өйрәнәчәк:**

• мәгънәсен ачыкларга кирәк булган сүзләрне табарга;

• текст буенча яки аңлатмалы сүзлек ярдәмендә сүзнең мәгънәсен аңлатырга;

**Укучы мөмкинлек алачак:**

• тексттагы кабатлауларны булдырмас өчен синонимнар эзләргә;

• предметларны чагыштырганда, аларга төгәл характеристика бирү өчен антонимнар сайларга;
• тексттагы сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен аерырга (гади очраклар);
• текстта (җөмләдә) сүзләрнең урынлы куллану-кулланмавын аера белә;
• аралашканда кулланыр өчен, кирәкле сүзләрне дөрес сайлый.

**«Сүз ясалышы» бүлеге**

**Укучы өйрәнәчәк:**
• тамырдаш, кушма, парлы сүзләрне аерырга;
• сүзләрнең нигезен, тамырын, кушымчаларын табарга;
• сүзнең мәгънәсен үзгәртергә.

**Укучы мөмкинлек алачак:**
• тәкъдим ителгән алгоритм буенча сүзне сүз төзелеше ягыннан тикшерә белергә;
• сүзне сүз төзелеше буенча тикшерүнең дөреслеген исбатларга.

**«Морфология» бүлеге**

**Укучы өйрәнәчәк:**
• исемнәрнең мәгънәсен, сорауларын, грамматик билгеләрен (сан, килеш, 1,2,3 зат) танырга;
• сыйфатларның мәгънәсен, сорауларын, төрле дәрәҗә формаларын билгеләргә;
• синоним һәм антоним сыйфатларны билгеләргә;
• тәртип һәм микъдар саннарын мәгънәсен, сорауларын;
• зат, тартым, сорау, күрсәтү алмашлыкларын билгеләргә;
• фигыльләрнең мәгънәсен, сорауларын, барлык-юклык, хәзерге, үткән, киләчәк заманнар, зат-сан формаларын билгеләргә;

**Укучы мөмкинлек алачак:**
зат алмашлыклары, кайбер рәвешләр, бәйлекләр турында мәгълумат ала;
• исемнәрне морфологик яктан тикшерергә;
• морфологик анализ буенча тикшерүнең дөреслеген исбатларга;

**«Синтаксис» бүлеге**

**Укучы өйрәнәчәк:**
• җөмлә, сүзтезмә, сүзне аерырга;
• сүзтезмәдәге сүзләр арасында һәм җөмләдәге бәйләнешне ачыкларга;
• җөмләләрне әйтү максаты ягыннан классификацияләргә; хикәя, боерык, сорау җөмләләрне табарга;
• тойгылы һәм тойгылы булмаган җөмләләрне аерырга;
• җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен табарга;
• тиңдәш кисәкле җөмләләрне билгеләргә;
• эндәш сүзләрне билгеләргә.

**Укучы мөмкинлек алачак:**
• җөмләнең баш кисәкләрен табып, аларның нинди сүз төркеме белән белдерелүенә (иянең исем яки зат алмашлыгы, хәбәрнең хикәя яки боерык фигыль, тартым алмашлыгы) белән мисаллар китерә белергә, тексттан баш кисәкләрне күрсәтә белергә;

• җөмләнең иярчен кисәге – тәмамлыкны һәм аергычны аера белергә һәм аергычның сыйфат, сан белән белдерелүен күрсәтә белергә;

**«Бәйләнешле сөйләм үстерү» бүлеге**

**Укучы өйрәнәчәк:**

• көндәлек тормышта сөйләм этикетын һәм телдән аралашу кагыйдәләрен истә тотарга;
• үз фикерен җиткерү, аралашу ситуациясен истә тотып, дәлилләү;
• текстны мөстәкыйль рәвештә мәгънәви кисәкләргә бүлергә һәм исем куярга;
• текстның планын төзергә.
• хат, открытка яки записка кебек зур булмаган текстлар язарга.

**Укучы мөмкинлек алачак:**

• укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә;
• сөйләм әдәбе сакланмаган текстларны төзәтә;
• геройларга характеристика бирергә (укытучы ярдәме белән);
• бирелгән темага текстны дәвам итәргә;
• план яки рәсем буенча хикәя төзергә;

**Рус мәктәбендә укучы татар балаларның татар теленнән белем һәм күнекмәләрен тикшерү төрләре**

| | Эш төрләре | Сыйныфлар | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Тыңлап алу | - | **0,5-1 мин.** | **1-1,5 мин** | **1,5-2 мин** |
| 2 | Диалогик сөйләм | **3** | **4** | **5** | **6** |
| 3 | Монологик сөйләм | **4** | **5** | **6** | **7** |
| 4 | Күчереп язу (җөмлә саны) | **1-2** | **3-4** | **5-6** | **7-8** |
| 5 | Сүзлек диктанты | **-** | **6 сүз** | **8-9 сүз** | **10-12 сүз** |
| 6 | диктант | **-** | **25-30** | **30-35** | **35-40** |
| 7 | Изложение (сүзләр саны) | **-** | **-** | **40-45** | **50-55** |
| 8 | Сочинение (җөмлә саны) | **-** | **-** | **6-7** | **7-8** |

**Тыңлап аңлауны бәяләү**

“5”- тыңланган татар сөйләмен тулаем аңлап, төп эчтәлеген сөйләп бирә алса;
“4”- пөхтә, төгәл язылган, әмма 1 – 3 төзәтүе, яки 1- 2орфографик хатасы булса;
“3”- пөхтә, төгәл язылмаган, 4 – 5 төзәтүе яки 3 – 5 орфографик хатасы булса;
“2”- пөхтә, төгәл язылмаган, 6 яки артыграк орфографик хатасы булса.

**Контроль күчереп язуны бәяләү**

“5”- пөхтә, төгәл орфографик хатасыз язылган эшкә;
“4”- тыңланган татар сөйләмен аңлап, эчтәлеген якынча дөрес сөйли алса;
“3”- тыңланган татар сөйләмен аңлап, эчтәлеген өлешчә генә сөйләп бирә алса; ;
“2”- тыңланган татар сөйләменең эчтәлеген тулаем аңламаганда.

**Диктантларны бәяләү:**

“5”- пөхтә, төгәл язылган 1 орфографик хатасы булырга мөмкин;
“4”- пөхтә, төгәл язылган , 2 - 3 орфографик хатасы булса;
“3”- пөхтә, төгәл язылмаган, 4 – 6 орфографик хатасы булса;

“2”- пөхтә, төгәл язылмаган 7 яки артыграк орфографик хатасы булса.

**Сүзлек диктантны бәяләү**

“5” – диктант пөхтә итеп язылган, хатасы юк;
“4” – пөхтә, төгәл язылган, әмма 1 – 3 төзәтүе яки 1 – 2 орфографик хатасы бар;
“3”- пөхтә, төгәл язылмаган, 4 – 5 төзәтүе яки 3 – 5 орфографик хатасы булса;
“2”- пөхтә, төгәл язылмаган 6 яки артыграк орфографик хатасы булса.

**Изложение һәм сочинениеләрне бәяләү**

1. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле итеп ачылса; җөмләләр грамматик яктан дөрес төзелсә; хаталар булмаса яки 1 орфографик (1 җөмлә төзелешендә) хата җибәрелсә, **«5» ле** куела.
2. Эчтәлек дөрес ачылып та, эзлеклелек сакланмаса яки пөхтә башкарылып, эзлеклелек булып та, сүз сайлауда һәм җөмлә төзүдә 2—3 хата булса, **«4» ле** куела.
3. Текстның яки рәсемнең төп эчтәлеге бирелеп тә, эзлеклелек сакланмаса; 4—6 орфографик, пунктуацион хата җибәрелсә; сүзләр кулланганда һәм җөмләләр төзегәндә, 4—5 төгәлсезлек китсә, **«3» ле** куела.
4. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле ачылмаса; 7—10 орфографик, пунктуацион хата җибәрелсә; сүзләр кулланганда, җөмләләр төзегәндә, 6—7 тупас хата китсә, **«2» ле** куела.

Хаталарны классификацияләү (тупас, тупас булмаган хаталар) милли мәктәпләр өчен эшләнгән нормаларга туры килә.

**Грамматик күнекмәләрне бәяләү**

Грамматик форма һәм конструкцияләрне гамәлдә дөрес куллануны бәяләү телгә өйрәтүнең мөһим күрсәткечләреннән санала.

Укучыларның белем һәм күнекмәләре телдән һәм язма формада тикшерелә.

**Грамматик белемнәрне бәяләү**

1. Ана телендә өйрәнелгән грамматик күренешләрне сөйләмдә дөрес кулланса; тупас булмаган 1—2 хата җибәрсә; укытучыга 1—2 ачыклаучы сорау бирергә туры килсә, **«5»ле** куела.
2. Төп таләпләрне үтәп тә, 2 грамматик хата ясаса, ләкин өстәмә сораулар саны 3 тән артмаса, **«4» ле** куела.
3. Грамматик форма һәм синтаксик конструкцияләрне сөйләмдә куллана белсә, ләкин 4—5 грамматик хата җибәрсә, **«3» ле** куела.
4. Грамматик күнекмәләр начар үзләштерелсә; грамматик кагыйдәләрне сөйләмдә куллана алмаса; хаталар 6 дан артып китсә, **«2» ле** куела.

**Укыту процессының укыту-методик тәэмин ителеше**

1. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11нче сыйныфлар. Ч.М. Харисова, К.С. Фәтхуллова, З.Н. Хәбибуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.
2. Әлифба: рус телендә башлангыч белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар телендә сөйләшүче балалар өчен). Гарифуллина Ф.Ш. .- Казан. “Мәгариф –Вакыт” нәшрияты, 2012.

3. Татар теле: рус телендә башл.гомуми белем бирү мәкт. 1 нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен) / Ф.Ф Харисов, Ф.М. Хисамова, Ч.М. Харисова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013.
4. Татар теле: рус телендә башл.гомуми белем бирү мәкт. 2 нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен) / Ф.Ф Харисов, Ф.М. Хисамова, Ч.М. Харисова. – Казан: Татар. кит. нәшр. 2012.
6. Татар теле: рус телендә башл.гомуми белем бирү мәкт. 3 нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен) / Ф.Ф Харисов, Ф.М. Хисамова, Ч.М. Харисова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013.
7. Татар теле: рус телендә башл.гомуми белем бирү мәкт. 4 нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен) / Ф.Ф Харисов, Ф.М. Хисамова, Ч.М. Харисова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013.

**Өстәмә әдәбият:**

1. I – IV нче сыйныфлар өчен татар теленнән диктантлар ”М.Х.Хәсәнова, Л.И.Галиева, С.С.Мөхәммәтшина, Т.Н.Садыйкова. Казан: Мәгариф, 2006.
2. “Башлангыч сыйныфлар өчен класстан тыш уку программасы һәм дәрес эшкәртмәләре” Р.К.Галләмова. –Казан: РИЦ «Школа». 2008.
3. 2014/2015 нче уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре: методик тәкъдимнәр/ төз. Д.Ш.Гыйльманов. – Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2014.
4. Электрон кулланма “Кызыклы татар теле” (интерактив кроссвордлар) Закирова Н.Н
5. Уйларыбыз − ак кәгазьдә...: Сочинениеләр җыентыгы. Гыймадиева Н.С.Галләмова Р.В.− Казан: «Гыйлем» нәшрияты, 2008.
6. Үзебез язабыз: Башлангыч сыйныфлар өчен сочинениеләр.- Казан: “Гыйлем” нәшрияты, 2008.
7. Әлифба белән ничек эшләргә? Максимов Н.В., Степанова А.А.
8. Казан, «Мәгариф» журналы.
9. Татар теленнән диктантлар, М.Х.Хәсәнова, Л.И.Галиева, С.С.Мөхәммәтшина, “Мәгариф” нәшрияты, 2006.
10. Татар теле дәресләре. З.И.Җамалетдинова.
11. Татар теле. Мавыктыргыч лексикология. Взаимосвязанное обучение русскому и татарскому языкам, Ф.М.Мусин, Т.К.Мусина, “Мәгариф” нәшрияты, 2001.
12. Татар теленнән эш дәфтәре: Венера Мусина, Алсу Якупова, Рузилә Галләмова.
13.Татар теленнән диктантлар, М.Х.Хәсәнова, Л.И.Галиева, С.С.Мөхәммәтшина, “Мәгариф” нәшрияты, 2006.
14. Башлангыч сыйныфлар өчен татар теленнән сочинениеләр, Сафина С.Р., Гыймадиева Н.С., “Яңалиф” нәшрияты, 2005.

**Укыту процессының материаль-техник тәэмин ителеше**

**Компьютер һәм мәгълүмати коммуникатив чаралар**

**Китапханә фонды**

1-4 сыйныфлар өчен укыту-методик комплекты (дәреслекләр)

**Укытуның техник чаралары**

1. Сыйныф тактасы.
2. Экран.

3. Персональ компьютер.
4. Мультимедия проекторы.
5. Тавыш колонкалары.

**Күрсәтү материаллары**

Предмет буенча таблицалар.

**Сыйныф җиһазлары:**

Парталар.
Укытучы өстәле, тумбасы.
Дәреслекләр, дидактик материаллар өчен шкафлар.

**Медиаресурслар**

1. http://belem.ru/ - татар телендә интернет белем үзәге
2. www.ed.gov.ru – сайт Министерства образования и науки РФ
3. www.mon.tatar.ru – сайт Министерства образования и науки РТ
4. www.fipi.ru – Федеральный институт педагогических измерений
5. Edu.tatar.ru /- онлайн биремнәр
6. http://vk.com/uchteki/balarf -татар теленнән биремнәр
7. http://gzalilova.narod.ru/ - Г. Җәлилова сайты
8. http://pedsovet.org –Педсовет (медиотека)
9. Tatarshool.ru. Әлифба. Татар теле. Әдәби уку дәресләре буенча онлайн биремнәр.

## 1 нче сыйныф

### 1 нче сыйныф өчен максат һәм бурычлар:

**«Телдән әзерлек чоры»нда** татар әдәби тел нормаларына өйрәтү өчен, унбер тема һәм аларның тасвирламалары бирелде. Алар буенча әңгәмәләр оештыру — бик җаваплы эш, чөнки балаларның күбесе беренче тапкыр тематик принцип нигезендә системалы рәвештә татарча сөйләшү күнекмәләре булдыра башлый. Шуңа күрә эшнең ни дәрәҗәдә нәтиҗәле булачагы әлеге чорның уңышлы үтүенә бәйле.

«Телдән әзерлек чоры» өчен сүзләр үрнәк буларак тәкъдим ителә. Кайсы дәрестә ничә һәм нинди сүз өйрәнүне укытучы үзе хәл итә, чөнки татар теле — рус җирлегендә яшәсә дә, татар баласы өчен ана теле, андагы күп сүзләр укучыга таныш булырга мөмкин.

«**Әлифба чоры»**нда татар һәм рус телләрендә бердәй әйтелешле авазлар кергән сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү, алар белән иҗекләр, сүзләр, сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзетү күз уңында тотыла. Әйтелешнең үзенчәлекләрен балаларга күрсәтүдә техник чаралардан файдалану, дәресләрдә төрле уеннар уйнау да уңай нәтиҗәләргә китерә.

Укучылар аваз белән хәрефне аерырга өйрәнәләр, сүз басымы, исем, сыйфат, фигыль кебек сүз төркемнәре турында башлангыч мәгълүмат алалар. Сөйләм берәмлеге буларак җөмлә, аларны төрле интонация белән әйтү, сүзләрдән җөмләләр, җөмләләрдән кечкенә хикәяләр төзи белү күнекмәләре бирү дә әһәмиятле. Укучыларның татар телен белү дәрәҗәсен исәпкә алып, укытучы дәресләрдә татар һәм рус теле үзенчәлекләренә тукталырга, тәрҗемә өлкәсенә караган биремнәр дә тәкъдим итәргә тиеш.

Татар теленең үзенчәлекле сузык [ө], [ү] һәм тартык [җ], [ң], [һ]

авазлары әйтелешен өйрәтү укытучының даими игътибар үзәгендә булырга тиеш. Авазларның әйтелешен әдәби тел нормалары буенча өйрәнү системалы алып барыла. Бу сыйныфта укучылар шулай ук телебезнең төп фонетик законын — сингармонизмны да өйрәнә. Әлеге законны белү алга таба сүз төркемнәренә төрле кушымчаларның ялгану тәртибен аңлау һәм өйрәнүдә ярдәм итәчәк.

Рус мәктәбендә укучы татар балаларының сөйләменә хас булган ялгышларны төзәтү, аларны булдырмау өчен, программада «Кара-каршы сөйләшү үрнәкләре», «Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү өчен үрнәк текстлар» тәкъдим ителә. Укучыларның белем дәрәҗәләрен исәпкә алып, укытучы аларны катлаулырак итеп тә төзергә мөмкин. Әмма сөйләм телен үстерү буенча эш даими, һәр дәрестә алып барылырга тиеш. Моның өчен балаларга атап чыгарыла торган газета-журналлардан, китаплардан файдалану да уңай нәтиҗә бирәчәк.

Программада, һәр сыйныфта бәйләнешле сөйләм үстерү өчен, аерым эш төрләре һәм темалар тәкъдим ителә. Укытучы укучылардан сүзлекчә булдыруны һәм өйрәнелә торган сүзләрне махсус дәфтәргә язып баруны таләп итәргә тиеш. Еш кына шул сүзләр белән сүзтезмә һәм җөмләләр төзү, аларны диалог һәм монологлар төзүдә файдалану укучыларның сүз байлыгын арттырачак, бәйләнешле сөйләм оештыруга ярдәм итәчәк. Әлеге сүзлекне даими рәвештә тикшереп тору укучыларның эшли белү дәрәҗәсен өйрәнү өчен дә кирәк булачак.

Сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру төрле язма эшләр үтәгән вакытта да алып барыла. Аңлатмалы һәм сүзлек диктантлары, укытучы биргән җөмләләрне (яки зур булмаган текстны) күчереп язу, матур язу күнегүләрен үтәү кебек эшләр дә сөйләм телен үстерүгә ярдәм итә.
Сөйләм телен үстерү уку дәресләрендә дә дәвам иттерелә. Татар теле дәресләрендә укытучы халык авыз иҗаты үрнәкләреннән дә файдалана. Аерым алганда, табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр, санамышлар ятлау, аларны дәфтәрләргә дөрес һәм матур итеп язып кую да балаларны татарча аңлаешлы, әдәби нормаларга туры килердәй итеп сөйләргә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия булып тора.

Милли-төбәк компонентына караган материалларны активрак кулланырга кирәк. Дәресләрдә файдаланыла торган текстлар татар этнокультурасын, тарихын, гореф-гадәтләрен, йолаларын киңрәк чагылдырып, шулай ук төбәк (шәһәр, район, авыл) үзенчәлекләре, анда яшәүче аерым шәхесләр, табигый географик аермалыклар да истә тотылырга, кыскасы, шундый мәгълүматлар татар теле дәресләрендә үз урынын алырга тиеш.

Укучыларны татар мохитенә киңрәк җәлеп итү, аларның мәгълүматлылыгын киңәйтү өчен, дәресләрдә күренекле татар язучыларының әсәрләреннән өзекләр куллану (аутентик текстлардан файдалану, татар композиторлары, рәссамнары һәм башка сәнгать әһелләре турында әңгәмәләр оештыру) нәтиҗәле булачак.

Программа рус мәктәпләрендә укучы татар балаларын укыту өчен төзелгәнлектән, балаларның рус теле дәресләрендә алган белемнәре дә истә тотылды. Шуңа күрә укытучы татар теленә хас күренешләрне аңлатканда, аларны рус теле белән чагыштырып күрсәтергә тиеш. Бу эш программада даими рәвештә искәртеп барыла. Эшне болай оештыру, ягъни укучыларның алган белемнәренә таяну, беренчедән, ике телгә дә хас булган һәм аермалы якларны гамәли максаттан

ассызыклау булса, икенчедән, алган белемнәрне ныгыта, тирәнәйтә; өченчедән, яңа материалны аңлатуга вакытны күбрәк калдыра.

**Укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлваштыруга нигезләнгән педагогик технологияләр:** проблемалы укыту технологиясе; күрсәтмәле-аңлатмалы технология; коммуникатив технология; шәхескә якын килү технологиясе; уен технологиясе;

**Уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр:** алга китеп укыту технологиясе; үстерешле белем бирү технологиясе; концентрик белем бирү технологиясе

**Телдән әзерлек чоры – 8 сәгать**

**Темалар һәм аларның тасвирламалары**

**1. Танышу**

Җөмләләрнең мәгънәләрен аңлап, *Син кем? Исемең ничек? Ул кем? Ул Саматмы? Бу кем? Аның исеме ничек? Сиңа ничә яшь?* кебек сорауларга җавап бирү.

*Әйе, юк, түгел* сүзләре белән раслау һәм инкарь җөмләләр төзү күнекмәләре тәрбияләү.

Зат алмашлыкларын кулланып, предметның кемгә караганлыгын белдерү.

Сүзләр: малай, кыз, исемем, исемең, исеме; утырыгыз; мин, син, ул, минем, синең, аның, миңа, сиңа, аңа; бу, кем, ничек, ничә; алты, җиде; исәнмесез, исәнме, сәлам, сау булыгыз; рәхмәт, әйе, юк, бар; *ә* теркәгече; *-мы, -ме* кисәкчәләре.

**2. Безнең мәктәп (сыйныф)**

Мәктәп, сыйныф укучылары һәм укытучы турында сөйләшү.

*Кем? нәрсә?* сорауларына җавап бирергә өйрәнеп, эшне үтәүчене билгеләү.

*Бу нәрсә?* соравына җавап бирү. Сыйныф бүлмәсендәге уку-язу әсбапларының исемнәрен әйтә белү.

*Кемнең?* соравына җавап биреп, предметның кемгә караганлыгын белдерү.

Предметның барлыгы яки юклыгы турында хәбәр итү.

*Нинди? кайсы?* сорауларына җавап биреп, әйбернең билгесен белдерү.

*Ничә?* соравына җавап биреп, предмет саны турында хәбәр итү.

*Кая? кайда?* сорауларына җавап биреп, әйбернең (кешенең) урыны турында хәбәр итү.

*Нишли?* соравына җавап биреп, предметның (затның эше турында хәбәр итү.

*Кайда?* соравына җавап биреп, эшнең үтәлү урыны турында хәбәр итү.

*Нәрсә укый?* соравына җавап биреп, эш-хәрәкәт объект турында хәбәр итү.

*Нәрсә белән?* соравына җавап биреп, эш-хәрәкәт корал турында хәбәр итү.

*Ничек?* соравына җавап кайтарып, эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен, формасын белдерү.

Саннарны актив кулланышка кертү. Сөйләмдә сан һәм исем тезмәләрен дөрес куллану.

Сөйләмдә ким җөмләләрне дөрес һәм урынлы куллану.
Сүзләр: мәктәп, сыйныф, бүлмә, укучы, укытучы, акбур, карандаш, ручка, китап, дәфтәр, пенал, сумка, дәрес, рәсем стена, шкаф, парта, тәрәзә, ишек, өстәл, урындык, чүпрәк такта; утыра, басып тора, укый, яза, ясый, җырлый, сорый җавап бирә, тыңлый, карый, ала, бирә, бара, керә, эшли; без нең, сезнең, аларның; нәрсә,

кая, кайда, нинди, нәрсә белән кемнең, нишли; зур, кечкенә; бер, ике, өч, дүрт, биш.
**3. Безнең гаилә**
Гаилә кешеләре турында хәбәр итү.
Аларның исеме турында хәбәр итү.
Аларның эш-хәрәкәте турында хәбәр итү.
Эш-хәрәкәтнең үтәүчесе турында хәбәр итү.
Эш-хәрәкәтнең үтәлү вакыты турында хәбәр итү.
Эш-хәрәкәтнең үтәлү урыны турында хәбәр итү.
Аларга карата *бар, юк* сүзләрен дөрес кулланып, җөмләләр төзү.
Гаилә кешеләренең һөнәре, белгечлеге турында хәбәр итү.
Өйдәге әйбер атамаларын әйтә белү.
Аларның билгеләре турында хәбәр итү.
Предметның саны турында хәбәр итү.
Аларның урыны турында хәбәр итү.
Сүзләр: гаилә, әти, әни, әби, бабай, абый, апа, энем,-сеңлем, табиб, инженер, шәфкать туташы, сатучы, бала караучы, тегүче, төзүче; өй, йорт; өстәл, урындык, шкаф, компьютер; ята, тора, йоклый, ял итә; кайчан; бүген, иртәгә, көндез; таза, ябык; алты, җиде, сигез, тугыз, ун.
**4. Ашамлыклар**
Бу темага караган атамаларны әйтү.
Милли ризыкларны санап күрсәтү, ал арны кертеп, гади җөмлә белән сорауларга җавап бирү.
Ризыкны әзерләүче (пешерүче) турында хәбәр итү.
*Белән* бәйлеге + *фигыль* тезмәсен дөрес куллану.
Ризыкның сыйфаты турында хәбәр итү.
Ризыкның составы турында сөйләшү.
Сүзләр: аш, ботка, токмач, чәй, икмәк, чәкчәк, гөбәдия, очпочмак, бәлеш, бавырсак, сөт, май, катык, шикәр; чәйнек, чынаяк, тәлинкә, кашык, чәнечке; килограмм, грамм; тәмле, тәмсез, кайнар, салкын, ачы, баллы, тозлы; пешерә, кыздыра, сала, өсти, эчә, ашый, кисә, бүлә, куя, ала, булыша.
**5. Кеше**
Тән төзелешенә караган атамаларны әйтә белү.
*Кайсы?* соравына җавап бирергә өйрәнү.
Аларның билгеләре турында хәбәр итү.
Предметның саны турында хәбәр итү.
Шәхси гигиенага караган эш-хәрәкәт турында хәбәр итү.
Бу эш-хәрәкәтне үтәүче турында хәбәр итү.
Эш-хәрәкәтнең объекты турында хәбәр итү.
Эш-хәрәкәт коралы турында хәбәр итү.
Эш-хәрәкәтнең үтәлү вакыты турында хәбәр итү.
Сүзләр: кеше, авыз, теш, борын, күз, колак, чәч, баш, аяк, кул, бармак; су, сабын, сөлге; юа, юына, сөртә; чиста, пычрак; уң, сул; кайсы; иртән, кичен.
**6. Өс-баш һәм аяк киемнәре**
Темага караган атамаларны әйтә белү.

Предметның кемнеке икәнлеге турында хәбәр итү.
Аның барлыгын яки юклыгын белдерү.
Предметның билгеләре турында хәбәр итү.
Аның саны турында хәбәр итү.
Темага караган предметларның эш-хәрәкәте турында хәбәр итү. Эш-хәрәкәтнең объекты турында хәбәр итү.
Сүзләр: күлмәк, алъяпкыч, яулык, чалбар, бияләй, тун, бүрек, итек, оек, ботинка; кия, сала, чишенә, элә, бәйли, тегә, чистарта; яңа, иске, ак, кара, зәңгәр.

**7.Уеннар**

Уеннар һәм уенчык атамалары турында хәбәр итү.
Аларның кемнеке икәнлеген белдерү.
Предметның барлыгын яки юклыгын белдерү.
Аның билгесен белдерү.
Предметның саны турында хәбәр итү.
Предметның урыны турында хәбәр итү.
Аңа бәйле эш-хәрәкәтне белдерү.
Эш-хәрәкәт объекты турында хәбәр итү.
Сүзләр: чана, чаңгы, тимераяк, туп, шар, уен, уенчык, курчак; уйный, ясый, ята, шуа, егыла, тора; матур, ямьсез, салкын, җилле, тайгак, шома, йомшак, каты.

**8.Авылда**

Яшелчә исемнәрен әйтә белү.
Хайван исемнәрен әйтә белү.
Темага караган предметларның билгеләре турында хәбәр итү.
Хайван, кош-кортларның саны турында хәбәр итү.
Аларның эш-хәрәкәте турында хәбәр итү.
Эш-хәрәкәтләрнең үтәүчесен белдерү.
Аларның объекты турында хәбәр итү.
Эш-хәрәкәтләрне үтәү коралы турында хәбәр итү.
Кыргый һәм йорт хайваннарының яшәү урыны турында хәбәр итү.
Яшелчә, җиләк-җимешләрнең үсү урыны турында хәбәр итү.
Сүзләр: авыл, урман, җир, бакча, алма, чия, карлыган, суган, кәбестә, кишер, бәрәңге, кыяр, помидор, җиләк, яшелчә бакчасы; лейка, көрәк; кызыл, яшел, сары, көрән, соры; сибә, казый, утырта, йөзә, оча, йөгерә, җыя; сыер, ат, сарык, тавык, әтәч, каз, үрдәк, балык, эт; төлке, бүре, аю, керпе, куян.

**9. Кошлар**

Кошлар исемен әйтә белү.
Безнең якта кышлаучы кошларны атау.
Җылы яктан кайтучы кошлар турында хәбәр итү.
Аларның яшәү урыны турында хәбәр итү.
Кош ларның табигатькә, кешеләргә китергән файдасы турында сөйләү.
Сүзләр: чыпчык, сыерчык оясы, карлыгач, сандугач, тукран, күке, песнәк, күгәрчен, ябалак, бөркет, торна, акчарлак, аккош, карабүрек, кара карга, карга, саескан, тургай; кош оясы, читлек, җимлек, җим; кычкыра, очып кайта, очып китә, сайрый, чыркылдый, чүпли.

**10. Шәһәрдә**

Шәһәр тормышына караган атамаларны әйтә белү.
Предметларның билгеләре турында хәбәр итү.
Предметларның исемнәре турында хәбәр итү.
Предметларның санын белдерү.
Аларның эш-хәрәкәтен белдерү.
Эш-хәрәкәтнең билгесен белдерү.
Эш-хәрәкәтнең үтәлү урынын белдерү.
Эш-хәрәкәтнең үтәлү вакытын белдерү.
Сүзләр: шәһәр, район, урам, трамвай, троллейбус, автобус, машина, тукталыш; йөри, туктап тора, кайта, яши; киң, тар; тиз, акрын; һәм.

**11. Бәйрәмнәр**

Бәйрәмнәрне санап күрсәтү.
Милли бәйрәм — Сабантуй турында сөйләү.
Бәйрәмнәрне уздыру вакыты турында хәбәр итү.
Бәйрәм белән котлау, бүләк тапшырганда әйтелә торган сүзләрне дөрес һәм урынлы куллану.
Бәйрәмнәргә карата хис-тойгыңны (мөнәсәбәтеңне) белдерү.
Сүзләр: туган көн, Яңа ел, 8 нче Март, Корбан бәйрәме, Спбантуй; бүләк, кунак, торт, битлек, Кыш бабай, Кар кызы, чыршы, әйлән-бәйлән, күчтәнәч; мәчет; ат чабышы, колга, капчык, көрәш; бәхетле, кадерле; бүләк итә, котлый, елмая, көлә, шатлана, бәйрәм итә, ихтирам итә, кунак итә, ярыша, җиңә.

## Әлифба чоры – 13 сәгать

Хәрефләрдән иҗекләр төзү, аннан соң иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр төзеп уку. Сүзтезмәләрдән җөмләләр төзү күнекмәләре тәрбияләү. Сүзләрне иҗекләргә бүлү.

Эчтәлеген аңлап, кирәкле урыннарда паузалар ясап, сүз басымын дөрес куеп уку.

Әлифба чорында татар һәм рус телләрендә бердәй әйтелешле авазлар *([б], [п], [д], [т], [ж], [ш], [з], [с], [и], [й], [л], [м], [н], [р], [у], [ф], [ц], [щ])* белән танышу, алар кергән сүзләрне дөрес уку.
*[а], [о], [V], [гъ], [къ], [х], [ч], [ы]* авазларының әйтелеш үзенчәлекләре һәм бу авазларны язуда дөрес күрсәтү.

Татар телендәге *[э], [ө], [ү], [җ], [ң], [һ]* авазлары кергән сүзләрне, сүзтезмәләр һәм җөмләләрне дөрес уку.

## Грамматика -8 сәгать

Дөрес язу һәм сөйләү күнекмәләре булдыру.

Иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес итеп әйтү һәм язу. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан-юлга күчерү.

Калын һәм нечкә сузыкларны белдерә торган хәрефләрнең дорес язылышы.

Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы.

Сүз басымын дөрес кую.

Татар телендәге исем, фигыль, сыйфат сүз төркемнәре белән таныштыру. Аларның мәгънәләрен аңлату, сорауларын ийтү; уртаклык һәм ялгызлык

исемнәрнең язылышындагы үзенчәлекне күрсәтү. Фигыльләрнең барлык-юклык формалары турында төшенчә бирү.

Җөмлә турында гомуми мәгълүмат бирү. Сөйләмне барлыкка китерүдә җөмләнең әһәмиятен аңлату. Анда сүзнең кем яки нәрсә турында баруын һәм алар турында нинди яңалык хәбәр итүен белдерә торган кисәкләрне күрсәтү. Аерым сүзләрдән жөмләләр төзү, сүзләр арасындагы бәйләнешне аңлату.

Төрле интонация белән әйтелгән җөмләләрдән соң куелган тыныш билгеләре белән таныштыру.

Бирелгән тексттан сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес итеп күчереп язу. Аннары аларны укытучы әйтүе буенча язу, ул тәкъдим иткән сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзеп язу.

Аерым темалар буенча өйрәнгән сүзләрне, сүзтезмә һәм жөмләләрне диктант итеп язу күнекмәләрен булдыру өстендә даими эшләү. Матур язу күнегүләрен үтәү. Сөйләм күнекмәләре булдыру өстендә даими эшләү.

**Бәйләнешле сөйләм үстерү - 3 сәгать**

Иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзеп әйтү. Терәк сүзләр ярдәмендә җөмләләр төзү.

Аерым темалардагы сүзләрне кертеп, тәкъдим ителгән грамматик конструкцияләр нигезендә сүзтезмәләр, җөмләләр төзү, сорауларга җаваплар бирү, 3-4 җөмләдән торган бәйләнешле сөйләм оештыру.

Рәсемнәргә карата сораулар бирергә өйрәнү һәм аларга җавап кайтару, рәсем буенча кечкенә хикәяләр төзергә өйрәнү.

Шигырь, мәкаль, әйтем һәм табышмаклар ятлау.

Татар сөйләм этикетына хас булган сүзләрне дөрес кулланып, сөйләм оештыру (танышканда, саубуллашканда, табын артында утырганда, рәхмәт әйткәндә, мөрәҗәгать иткәндә, гафу үтенгәндә, тәбрикләгәндә һ.б. очракларда)

**Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү өчен үрнәк текстлар**

Мин — Илназ. Минем фамилиям — Мортазин. Әтиемнең исеме — Раиф, әниемнеке — Фәния. Энем Нияз исемле. Гаиләбез тату яши.

Без дәрестә татарча сөйләшәбез. Минем «Әлифба» китабым бар. Укытучы рәсем буенча сораулар бирә. Мин җаваплар бирәм. Миңа Илназ да булыша. Мин Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырен яттан өйрәндем. Бу шигырь миңа бик ошый.

Минем әнием — укытучы. Ул мәктәптә татар теле укыта. Әтием — инженер. Ул заводта эшли. Абыем — студент. Ул табиб булачак. Апам — укучы. Ул җиденче сыйныфта укый. Күргәнегезчә, безнең гаилә шактый зур.

Илфат — укучы. Ул беренче сыйныфта укый. Иртә белән физик күнегүләр ясарга ярата. Аннан соң битен юа, тешләрен чистарта, урын-җирен җыештыра. Иртәнге ашны ашагач, мәктәпкә китә. Илфат — бик акыллы һәм тәртипле малай.

Казанның Бауман урамында «Чәй йорты» бар. Анда Һәрвакыт милли ашамлыклар була. Мин чәйне чәкчәк белән чәй эчәргә яратам. Бүген әнием миңа гөбәдия, ә үзенә өчпочмак пешерде. Аннары без тәмләп чәй эчтек.

Әтисе Гөлшатка кием шкафы сатып алды. Гөлшат киемнәрен шунда элеп куйды. Яңа шкаф аңа бик ошады. Ул уңайлы һәм матур итеп эшләнгән.

Кышның салкынча бер көне. Балалар урамда уйныйлар. Илгиз белән Гөлназ

чаңгы шуа. Миләүшә тимераякка баскан. Әнә ике малай таудан шуып төшәләр. Балалар шау-гөр киләләр. Аларга бик күңелле.

Дәү әнием авылда яши. Җәен без аңа кунакка кайтабыз. Авылда табигать бик матур. Урман ерак булса да, авыл яныннан гына ике елга ага. Без анда су коенабыз. Дәү әнинең бакчасында төрле яшелчәләр, җиләк-җимешләр үсә. Озакламый кара карлыган, крыжовник, кура җиләге өлгерер. Аннары кыяр, помидор да уңыш бирә башлар.

Көз җитте. Кырлар бушап калды. Агачлар яфракларын койдылар. Тракторлар җир сөрә. Һавада кошлар күренә. Алар, минемчә, җылы якка китәргә җыеналар. Я, әйтеп күрсәт әле, безнең якларда нинди кошлар кышлыйлар?

Казан — зур шәһәр. Ул — Татарстанның башкаласы. Анда бер миллионнан артык кеше яши. Казан — тарихи шәһәр. Анда истәлекле урыннар бик күп. Аңа мең ел тулды. Казан Россиянең иң борынгы шәһәрләреннән санала. Анда трамвайлар, троллейбуслар, автобуслар йөри. Казанда метро да бар. Урамда машиналар да күп. Мин башкалабызны яратам.

Сабантуй — татарларның милли бәйрәме. Бу бәйрәмне башка халыклар да бик ярата. Аны язгы чәчү беткәч уздыралар. Сабантуйда көрәшәләр, җырлыйлар, бииләр, озын колгага менәләр, капчык киеп йөгерәләр. Шома агачка утырып, капчык белән сугышу тамашасы бик кызык. Чүлмәк вату, ат чабышы да халыкка бик ошый. Җиңүчеләргә бүләкләр бирәләр. Бу бәйрәм бик күңелле уза.

**Сөйләм үстерү өчен темалар**

Танышу
Безнең мәктәп (сыйныф).
Бәйрәмнәр.
Безнең гаилә.
Ашамлыклар.
Кеше.
Өс-баш һәм аяк киемнәре.
Уеннар.
Авылда.
Кошлар.
Шәһәрдә.

**Контроль эшләр графигы**

| № диктантлар | Контроль эшнең темасы | Якынча үткәрелергә тиешле дата |
|---|---|---|
| 1 кереш | - | |
| 2  I чирек | - | |
| 3 II чирек | - | |
| 4 II чирек | - | |
| 5 IV чирек | 2018-2019 нчы уку елы өчен 1 сыйныф курсы буенча йомгаклау контроль эше. | 14.05 |

**2 нче сыйныф**

**2 нче сыйныф өчен максат һәм бурычлар:**

1. Татар алфавитын яттан белү; сүзләрне һәм фамилияләрне алфавит тәртибендә язу;
2. Сузык авазларны калын һәм нечкә, тартык авазларны яңгырау һәм саңгырау тартыкларга аера белү; ъ һәм ь , я, ю, е хәрефләре булган сүзләрне дөрес уку һәм язу; татар телендәге сүзләрнең сингармонизм законына буйсынуын яки буйсынмавын аңлау;
3. Бирелгән иҗекләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү; татар теленең үзенчәлекле авазларын язуда хәрефләр белән күрсәтә белү.
4. Сүзләрне иҗеккә дөрес итеп бүлү; татар сүзләренә басым кую; рус сүзләре белән чагыштырып аңлата белү.
5. Җөмләләрдән исем, сыйфат, фигыльләрне табу. Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формаларын аеру, фигыльнең юклык заман кушымчаларын билгеләү.
6. Җөмләнең баш кисәкләрен билгеләү, аларның урнашу тәртибен аңлату, татар җөмләсе белән рус җөмләсе арасындагы аерманы күрсәтә белү;
7. Дәреслектә бирелгән текстларны дөрес, сәнгатьле укырга; текстлар буенча укытучы биргән сорауларга җавап бирергә;
8.Тизәйткеч, санамыш, табышмак, мәкаль-әйтемнәр ятлау.

**Программаның эчтәлеге һәм предмет нәтиҗәләре:**

**1нче бүлек. 1 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау – 6 сәгать**

Сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм юлдан-юлга күчерү. Аерым сүзләр һәм сүзтезмәләрне, җөмләләрне дөрес итеп уку һәм язу . Иҗекләрдән сүзләр, сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзеп әйтү һәм язу. Кем? Нәрсә? Нинди? Кайсы? Нишли? сорауларына җавап бирә торган сүзләр. Баш хәреф белән языла торган сүзләрне кабатлау. Дәрестә өйрәнелә торган язучыларның исем фамилияләрен дөрес язу.

**Укучы өйрәнәчәк:**

-аерым сүзләр һәм сүзтезмәләрне, җөмләләрне дөрес итеп укырга һәм язарга; бирелгән иҗекләрдән сүзләр, сүзтезмәләр төзеп әйтергә;

-тәкъдим ителгән җөмләләрне дөрес итеп күчереп язарга;

-сүзләрне юлдан-юлга күчерергә;

-Кем? Нәрсә? Нинди? Кайсы? Нишли? сорауларына җавап бирә торган сүзләрне табу, алар белән җөмләләр төзергә;

-баш хәреф белән языла торган сүзләрне белергә;

**Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак:** бирелгән иҗекләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзергә; баш хәреф белән языла торган сүзләр уйлап язарга; сорау сүзләр белән җөмләләр төзергә; кем? нәрсә? нинди? кайсы? нишли? сорауларына җавап бирә торган сүзләргә мисаллар китерә белергә, сүзтезмәләр төзергә; сорауларга җавап бирергә.

**2нче бүлек. Авазлар һәм хәрефләр – 24 сәгать**

Алфавит. Сузык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар. Сингармонизм законы. Татар теленең үзенчәлекле сузыклары [ә] , [ө], [ү] һәм аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. [а], [э], [о], [ы] сузыкларын белдерә торган хәрефләр; я, ю, е хәрефләре; тартык авазлар. Яңгырау һәм саңгырау тартык авазлар. Татар теленең үзенчәлекле тартыклары.[w], [гъ] [къ], [х], [ч] тартыклары, [ж], [ң], [һ] тартыклары булган сүзләр; ц, щ булган сүзләр; ъ, ь булган сүзләр;

**Укучы өйрәнәчәк:**

татар теленең алфавитын; сузык авазларны, тартык авазларны, аларны дөрес әйтергә; [а],[ә], [о], [ы] сузыкларын белдерә торган хәрефләр; я, ю, е хәрефләре, бу хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку; [w], [гъ] [къ], [х], [ч] тартыкларын дөрес әйтергә, [ж], [ң], [һ] тартыклары булган сүзләрне дөрес укырга; ц, щ булган сүзләрне дөрес укырга; ъ, ь булган сүзләрне дөрес укырга; сыйныфташларның фамилияләрен алфавит тәртибендә язарга; татар теленең үзенчәлекле сузыклары һәм аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышын белергә; [а], [ә], [о], [ы] авазларын белдерүче хәрефләрнең дөрес язылышы; тартыкларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышын аңлатырга; аңлатмалы һәм сүзлек диктантлар язарга.

**Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак:**

-бер төркемгә караган предметларны алфавит тәртибе буенча урнаштыра белергә; җөмләдәге сүзләрнең транскрипцияләрен язарга; сүзләрне аваз ягыннан тикшерергә; аның дөреслеген тикшерергә; сингармонизм законына буйсынмаган яки буйсынган сүзләр уйлап язарга;

### 3нче бүлек. Сүз - 2 сәгать

Сүзләрне иҗекләргә бүлү; татар телендә сүз басымы; рус телендәге сүз басымының урыны.

**Укучы өйрәнәчәк:**

-сүзләрне иҗекләргә бүләргә; иҗек калыплары барлыгын белергә; татар телендә сүз басымы турында мәгълүматлы булырга.

**Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак:** тәкъдим ителгән сүзләргә дөрес итеп басым куярга; иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр төзеп язарга һәм аларны кулланып җөмләләр төзергә.

### 4нче бүлек. Морфология - 10 сәгать

Исем, аның мәгънәсе, сораулары, берлек һәм күплек сан формалары; фигыль, аның мәгънәсе, сораулары, заман формалары , сыйфат, аның мәгънәсе, сораулары, сыйфатларның сыйфатланмышы.

**Укучы өйрәнәчәк:**

-исем, аның мәгънәсе, сораулары, берлек һәм күплек сан формаларын дөрес итеп кулланырга; күплек сан кушымчаларының дөрес язылышы, аларны рус теле белән чагыштырырга; фигыль, аның мәгънәсе, сораулары, заман формалары

барлыгын, рус теле белән чагыштыра белергә; сыйфат, аның мәгънәсе, сораулары, сыйфатларның сыйфатланмышы барлыгын аңларга; татар һәм рус телләрендә сыйфатларның сыйфатланмышка иярү үзенчәлегенә төшенергә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак:** бирелгән җөмләләрдән, әзер тексттан өйрәнгән сүз төркемнәрен табарга, аларны русчадан татарчага тәрҗемә итәргә; сыйфат+сыйфатланмышка мисаллар уйлап язарга; фигыльләрне заман формаларында затсанда төрләндерергә; барлык сүз төркемнәрен кертеп җөмләләр төзергә.

**5 нче бүлек. Синтаксис - 6 сәгать**

Сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү; җөмләнең баш кисәкләре турында мәгълүмат бирү, аларның урнашу тәртибен күзәтү, аны рус теле белән чагыштыру; бирелгән сүзләр һәм сүзтезмәләр белән җөмләләр төзү. Тәрҗемә күнекмәләре булдыру.

**Укучы өйрәнәчәк:**

-сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзергә; җөмләнең баш кисәкләре турында мәгълүмат бирергә, аларның урнашу тәртибен күзәтергә, аны рус теле белән чагыштырырга; татарчадан русчага, русчадан татарчага тәрҗемә итәргә; **Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак:** тәкъдим ителгән терәк сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзергә; тексттагы җөмләләрнең баш кисәкләрен табып аңлатырга; җөмлә чикләрен билгеләргә; тәкъдим ителгән терәк сүзләрне кулланып, 15-20 сүздән торган хикәя төзергә.

**6 нчы бүлек. Ел буена үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау -4**

**Укучы өйрәнәчәк:** Ел буена үткәннәр буенча укытучының сорауларына дөрес итеп җавап биреп, күнегүләр өстендә эшли белергә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак:** алган белемнәрне төркемли, кирәклесен аерып ала, өйрәнгәннәрне куллана белергә.

**7 нче бүлек. Бәйләнешле сөйләм үстерү - 11 сәгать**

Укытучының (иптәшеңнең) сорауларын аңлап, гади җөмләләр белән җавап бирү. Укытучы тәкъдим иткән темага 4-6 җөмлә төзеп әйтү, бирелгән диалогны (монологны) дәвам итү. Укылган өзекнең төп фикерен үз сүзләрең белән әйтү. Темаларны өйрәнү вакытында аңлатмалы һәм сүзлек диктантлары язу. Аерым рәсемнәр һәм әйберләрне сурәтләп биргәндә, исем, сыйфат, фигыльләрне дөрес куллану. Тизәйткеч, санамыш, табышмак, мәкаль-әйтемнәрне ятлау. Матур язу күнекмәләре булдыру.

**Укучы өйрәнәчәк:** укылган текстның эчтәлеген үз сүзләрең белән сөйли белергә; исем бирергә; сорауларга җавап бирергә; сүзлек һәм аңлатмалы диктантлар язарга; тәкъдим иткән темага 4-6 җөмлә төзеп әйтергә, бирелгән диалогны (монологны) дәвам итәргә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак:** текстны өзекләргә булергә; план төзергә; план буенча текстның эчтәлеген сөйләргә; өзеккә төп фикереңне үз сүзләре белән әйтергә; укыган әсәр буенча сорауларга җавап бирергә; тизәйткеч, саналмыш, табышмак, мәкальәйтемнәрне яттан белергә; аерым рәсемнәр яки әйберләрне сурәтләгәндә исем, сыйфат һәм фигыльләрне дөрес кулланырга; бирелгән темалар буенча хикәяләр, сочинение, изложение язарга; тексттагы хаталарны табып төзәтә белергә; җөмләләрне дөрес тәртиптә урнаштыра белергә;

**Сөйләм үстерү өчен темалар:** Яңа уку елы белән! . Исәнме , мәктәп! Безнең сыйныф. . Татар теле дәресендә. Көз җитте. Урамда көз . Безнең гаилә бик тату. Яшелчә бакчасында. Милли ризыклар. Әниемә булышам. Яңа ел бәйрәме. Туган ягымда кыш. Саумы, җәй!

**Контроль эшләр графигы**

| № диктантлар | Контроль эшнең темасы | Якынча үткәрелергә тиешле дата |
|---|---|---|
| 1 кереш | | 18.09 |
| 2 I чирек | “Авазлар һәм хәрефләр” бүлеге буенча | 29.10 |
| 3 II чирек | “Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан юлга күчерү “ темасы бунча | 25.12 |
| 4 II чирек | “Сүз төркемнәре “ темасы бунча | 9.03 |
| 5 IV чирек | 2018-2019 нчы уку елы өчен 2 сыйныф курсы буенча йомгаклау контроль эше. | 20.05 |

## 3 нче сыйныф

## 3 нче сыйныф өчен максат һәм бурычлар:

1. Татар теленең үзенчәлекле сузык һәм тартык авазларын дөрес әйтә, бу авазлар булган сүзләрне дөрес итеп язуда күрсәтә белү.
2. Сүз мәгънәсе, туры, күчерелмә, охшаш, капма – каршы мәгънәле сүзләр турында мәгълүматлы булу.
3. Сүзләрне төзелешләре буенча тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә сүзләргә аера белү. Сүзләрнең тамырын һәм кушымчасын табу;
4. Сүзләрне сүз төркемнәре буенча исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль сүз төркемнәренә аера башлау.
5. Өйрәнгән сүз төркемнәрен кулланып, сүзтезмәләр, җөмләләр төзү.
6. Татар җөмләсе белән рус җөмләсе арасындагы аерманы күрсәтә белү.
7. Хикәя, сорау, өндәү, раслау, инкарь җөмләләрнең билгеләрен күрсәтә белү.
8. Җөмләнең баш кисәкләрен билгели белү.
9. Җөмләнең иярчен кисәкләреннән аергычны таный белү.

**Эш программасының эчтәлеге һәм предмет нәтиҗәләре:**

**1 нче бүлек. 1-2 сыйныфларда үткәннәрне кабатлау -4 сәгать**

Авазлар һәм хәрефләр. Сузык һәм тартык авазлар. Калынлык, нечкәлек билгеләре. Сүз басымы. Сүзләргә фонетик анализ ясау. Исем; фигыль; сыйфат; җөмләнең баш кисәкләре. Дөрес матур язу күнегүләре өстендә эшләү. Аңлатмалы һәм сүзлек диктантлары язу.

**Укучы өйрәнәчәк:** хәреф, аваз санын әйтә белергә; сузык авазларны тартык авазларны, калын – нечкә сузыкларны, яңгырау – саңгырауларны аера белергә; ь,ъ билгеләренең эшләрен, иҗекләр ясалышын; татар телендә сүз басымының урыны; исем, сыйфат, фигыльләрне аера; гади җөмләдә ия, хәбәрне күрсәтә;

**Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак:** сүздә, фразада басымны дөрес куярга;тәкъдим ителгән алгоритм буенча мөстәкыйль рәвештә сүзне фонетик яктан тикшерергә;сүзне фонетик яктан тикшерүнең дөреслеген исбатларга; исем; фигыль; сыйфат; җөмләнең баш кисәкләре буенча алган белемнәрне дөрес итеп куллана белергә; бирелгән җөмләләрдән, әзер тексттан өйрәнгән сүз төркемнәрен таба белергә.

## 2 нче бүлек. Сүз - 6 сәгать

Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Күп мәгънәле сүзләр. Синоним, омоним, антоним сүзләр.Сүзлекләр турында мәгълүмат бирү.Аларны тексттан табу, сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллана белү. Сүзлекләр турында мәгълүмат бирү һәм алар белән эшләргә өйрәтү.

**Укучы өйрәнәчәк:** сүзнең мәгьнәсе барлыгын; парлап бирелгән сүзләрдә туры һәм күчерелмә мәгънәләрне билгели; 2 - 3 сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре белән җөмләләр төзергә; 5 – 6 сүзгә синоним, антоним парлар әйтә белә;

**Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак:** тексттагы кабатлауларны булдырмас өчен синонимнар эзләргә; предметларны чагыштырганда, аларга төгәл характеристика бирү өчен антонимнар сайларга; тексттагы сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен аерырга (гади очраклар); сүзлекләрнең төрләре буенча алган белемнәрне дөрес итеп кулланып, алар белән эшли белергә.

## 3 нче бүлек. Сүз төзелеше һәм ясалышы - 7 сәгать

Тамыр һәм кушымча.Тамырдаш сүзләр. Тамыр һәм ясалма сүзләр.Татар һәм рус телләрендә сүзләргә кушымчаларның ялгану тәртибе һәм үзенчәлекләре. Кушма һәм парлы сүзләр.

**Укучы өйрәнәчәк:** сүзнең мәгьнәсе барлыгын; парлап бирелгән сүзләрдә туры һәм күчерелмә мәгънәләрне билгели; 2 - 3 сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре белән җөмләләр төзергә; 5 – 6 сүзгә синоним, антоним парлар әйтә белә;

**Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак**: тәкъдим ителгән алгоритм буенча сүзне сүз төзелеше ягыннан тикшерә белергә;сүзне сүз төзелеше буенча тикшерүнең дөреслеген исбатларга.

## 4 нче бүлек. Морфология - 22 сәгать

Исем турында өйрәнгәннәрне искә төшерү. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр. Исемнәрнең килеш белән төрләнүе. Берлек һәм күплек сандагы исемнәрнең килеш белән төрләнүе.

Сыйфат турында өйрәнгәннәрне искә төшерү. Синоним, антоним сыйфатлар. Аларны сөйләмдә дөрес куллану. Сыйфатларның исемне ачыклап

килүе, җөмләдәге роле. Татар телендә сыйфат белән сыйфатланмышның бәйләнеш үзенчәлекләре.

Сан. Аның мәгънәсе, сораулары. Саннарны сөйләмдә дөрес куллану. Татар телендә сан белән саналмышның бәйләнеш үзенчәлекләре.

Алмашлыклар. Зат алмашлыклары. Аларның мәгънәләре , килеш белән төрләнеше. Сорау алмашлыклары турында мәгълүмат бирү.

Фигыль. Аның заманнары. Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше, аларның сөйләмдә дөрес кулланышы. Рус телендәге фигыльләрнең заманнары һәм зат-сан белән төрләнешендәге үзенчәлекләр.

**Укучы өйрәнәчәк:** исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыльләрне аера исемнәргә күплек сан кушымчаларын дөрес куярга; ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне аерып күрсәтергә; килеш сорауларын, кушымчаларын аерырга; исемнәрне килеш белән төрләндерә; зат, сорау алмашлыкларын аера; сыйфат һәм сыйфатланмышны күрсәтергә ; кулланылышта еш очраучы сыйфатларга синоним, антонимнар табарга; кушма, тезмә саннарны дөрес язарга; сан, саналмышны билгеләргә; саналмышның берлек санда гына булуын; фигыльне исем, сыйфат, сан, алмашлыкларны аерырга; фигыльнең юклык формасын күрсәтергә; 3 заман формасын атарга; хәзерге заман хикәя фигыльне зат - сан белән төрләндерергә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак:** бирелгән җөмләләрдән, әзер тексттан өйрәнгән сүз төркемнәрен табарга, сыйфат белән сыйфатланмышка һәм сан белән саналмышка мисаллар уйлап язарга; барлык сүз төркемнәрен кертеп сүзтезмә, җөмләләр яки 6-8 җөмләдән торган хикәя төзергә;

**5 нче бүлек. Синтаксис - 10 сәгать**

Өйрәнелгән сүз төркемнәрен кулланып, сүзтезмә һәм җөмләләр төзү, аларны сөйләмдә дөрес куллану. Җөмләнең коммуникатив төрләре: раслау, сорау, өндәү һәм инкяр җөмләләр. Алар янында тыныш билгеләре. Инкяр итүнең төп формалары: хәбәр булып килгән фигыльдә юклык кушымчаларын, түгел кисәкчәсен, юк хәбәрлек сүзен куллану. Җөмләнең баш кисәкләре. Аергыч турында мәгълүмат бирү. Җөмләдә сүз тәртибе. Русча җөмләләрне татарчага тәрҗемә итү. Татар телендә җөмләдә сүз тәртибе (ия белән хәбәрнең, аергыч белән аерылмышның урыннары).

**Укучы өйрәнәчәк:** сүз, сүзтезмә, җөмләләрне аера; сүзтезмәләрнең төрләрен; хикәя, сорау, өндәү җөмләләрне аера, аларны төзи; җөмләнең иясен, хәбәрен, аергычны күрсәтә; ия белән хәбәрнең, аергыч белән аерылмышның урыннарын билгели;

**Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак:** тексттан баш кисәкләрне күрсәтә белергә; җөмләнең иярчен кисәге аергычны таба белергә; русча җөмләләрне татарчага тәрҗемә 43 итәргә; хикәя җөмлә, сорау һәм өндәү җөмләләр, раслау һәм инкарь җөмләләр янында тыныш билгеләрен дөрес куеп , түгел кисәкчәсен һәм юк хәбәрлек сүзен кулланып, 6-8 җөмләдән торган диалог төзергә;

**6 нчы бүлек. Ел буена үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау - 4 сәгать**

**Укучы өйрәнәчәк:** Ел буена үткәннәр буенча укытучының сорауларына дөрес итеп җавап биреп, күнегүләр өстендә эшли белергә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак:** алган белемнәрне төркемли, кирәклесен аерып ала, өйрәнгәннәрне куллана белергә.

**7 нче бүлек. Бәйләнешле сөйләм үстерү - 10 сәгать**

6-8 җөмләдән торган диалоглар төзи белү. Укыган яки тыңлаган өзекнең эчтәлеген тулы җөмләләр белән сөйли белү. Бирелгән тема буенча диалог төзү , монологик сөйләм оештыру. Башланган диалогны яки монологны дәвам итү.(төгәлләү). Матур язу күнекмәләрен үстерү.

**Укучы өйрәнәчәк:** текстлар өстендә эшли белергә; укылган текстларның үз сүзләре белән сөйли белергә, аларга исем бирергә; җөмләләрнең башын, ахырын билгели белергә;төрле диктантлар яза белергә, диалогларда катнаша белергә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинчелек алачак:** грамматик конструкцияләрне дөрес итеп кулланып, текстларның эчтәлеген сөйли белергә; укылган текстка үз фикерләрен әйтә белергә; төрле төрдәге диктантлар яза белергә; тексттагы хаталарны табып төзәтә белергә; җөмләләрне дөрес тәртиптә урнаштыра белергә;

**Контроль эшләр графигы**

| № диктантлар | Контроль эшнең темасы | Якынча үткәрелергә тиешле дата |
|---|---|---|
| 1 кереш | | 13.09 |
| 2 I чирек | “Авазлар һәм хәрефләр” бүлеге буенча | 25.10 |
| 3 II чирек | “Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан юлга күчерү “ темасы бунча | 20.12 |
| 4 II чирек | “Сүз төркемнәре “ темасы бунча | 20.03 |
| 5 IV чирек | 2018-2019 нчы уку елы өчен 2 сыйныф курсы буенча йомгаклау контроль эше. | 16.05 |

**IV СЫЙНЫФТА** СҮЗНЕҢ НИГЕЗЕ, ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕН ЯСАУЧЫ ҺӘМ ГРАММАТИК МӘГЪНӘНЕ ҮЗГӘРТӘ ТОРГАН КУШЫМЧАЛАР БЕЛӘН ТАНЫШАЛАР, СҮЗ ТӨЗЕЛЕШЕН ТИКШЕРҮ КҮНЕГҮЛӘРЕН ҮТИЛӘР. Татар теленең агглютинатив тел булуын истә тотып, сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен табуда укучыларга сингармонизм законын белү дә ярдәм итәчәк.

Сүз төркемнәреннән сан һәм зат алмашлыклары өстәлә, фигыль заманнары, хәзерге заман хикәя фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше өйрәнелә. Җөмләнең баш кисәкләре, аергыч турында мәгълүмат бирелә, аларны татарча сөйләмдә дөрес куллану, рус теленнән татарчага тәрҗемә итү дә киң урын ала. Рәсемнәр яки укылган өзекнең эчтәлеге буенча кечкенә инша яисә сочинениеләр язганда, укучылар татарча җөмләләрне дөрес төзү, җөмлә кисәкләрен тиешле тәртиптә куллану күнекмәләре булдыралар.

Исемнәрнең килеш, тартым белән төрләнеше өйрәнелә. Дәрестә укытучы тартымның татар теленә генә хас грамматик категория икәнлеген, рус телендә бу мәгънәне белдерә торган башка чаралар булуын аңлата. Билгеле, тартымны аңлату өчен, сүзләрне һәм җөмләләрне русчадан татарчага тәрҗемә итү дә файдалы була. Тик аерым очракларда төрле күрсәтмә әсбаплар яки мәгънәдәш сүзләр ярдәме белән төшендерү дә зарури. Тәртип һәм микъдар саннары, тартым алмашлыклары, боерык фигыль, үткән һәм киләчәк заман хикәя фигыльләр

турындагы материаллар татар телендәге сүз төркемнәрен шактый тулы күзалларга мөмкинлек бирәчәк.

Җөмләнең баш кисәкләре, аларның нинди сүз төркемнәре белән белдерелүен, сөйләмдә җәенке һәм җыйнак җөмләләрне дөрес куллану, иярчен һәм тиңдәш кисәкләр, җыючы һәм каршы куючы кайбер теркәгечләр, эндәш сүзләрне өйрәнү — барысы да бу сыйныфта җөмлә төзелеше турында бирелә торган мәгълүматның шактый күләмле булуын дәлилли. Билгеле, укытучы тел дәресләрендә өйрәнелә торган материалны уку дәресләрендә дә, төрле характердагы язма эшләрне үтәгәндә дә кабатлатырга тиеш, алар сөйләмне үстерү өчен тәкъдим ителгән темалар буенча эшләгәндә дә игътибардан читтә калмасын иде.

Укучыларны татар мохитенә киңрәк җәлеп итү, аларның мәгълүматлылыгын киңәйтү өчен дәресләрдә күренекле татар язучыларының әсәрләреннән өзекләр куллану (аутентик текстлар, татар композиторлары, рәссамнары һәм башка сәнгать әһелләре турында әңгәмәләр оештыру нәтиҗәле булачак.

**Укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлваштыруга нигезләнгән педагогик технологияләр**

- проблемалы укыту технологиясе;
- күрсәтмәле-аңлатмалы технология;
- коммуникатив технология;
- шәхескә якын килү технологиясе;
- уен технологиясе;

**Уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр**

- алга китеп укыту технологиясе;
- үстерешле белем бирү технологиясе;
- концентрик белем бирү технологиясе.

**Темалар һәм аларның тасвирламалары**

**1. I—III сыйныфларда үткәннәрне кабатлау – 16 сәгать**

I—III сыйныфларда авазлар һәм хәрефләр турында үткәннәрне кабатлау: сузык һәм тартык авазлар; татар һәм рус телләренең икесендә дә булган, әмма әйтелеше белән татар телендә аерылып торган авазлар; татар теленең үзенчәлекле авазлары; сүзләрнең басымын билгеләү; сүзләргә фонетик анализ ясау.

Сүзлекләр турында белешмә бирү. Аларның төрләре. Төзелү принциплары турында мәгълүмат. Төрле типтагы сүзлекләр белән эшләү. Сүзләрне (сүзтезмә һәм җөмләләрне) тәрҗемә итү.

Татар һәм рус телләрендә тамыр һәм кушымчаларның үзенчәлекләрен искә төшерү, өйрәнгәннәрне ныгыту.

Төрле сүз төркемнәрен (исем, сыйфат, фигыльләрне) ясаучы кушымчалар. Сүзнең нигезе.

Сүзләрнең грамматик мәгънәләрен үзгәртә торган мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларны (исемнәрдә — күплек сан, килеш, фигыльләрдә — юклык, заман, зат-сан) дөрес билгеләү күнекмәләрен булдыру. Сүз төзелешен тикшерү күнегүләрен үтәү.

Морфология һәм синтаксис буенча үткәннәрне кабатлау.

## 2. Морфология - 4 сәгать

Исем. Яңгырау, саңгырау һәм борын авазларына беткән исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Аларның дөрес әйтелеше, язылышы һам сөйләмдә дөрес кулланылышы.

Исемнәрнең тартым белән төрләнеше турында мәгълүмат. Тартымның берлек һәм күплек сан формалары, аларны сөйләмдә дөрес куллану. Тартым мәгънәсенең рус телендә бирелеше.

Сыйфатның дәрәҗә формалары, аларның дөрес язылышы. Рус телендәге сыйфат дәрәҗәләреннән аермасы.

Сан. Предметның төгәл микъдарын, саналу тәртибен белдерә торган саннар. Аларның сөйләмдәге әһәмияте, дөрес куллану күнекмәләре. Татар телендә саналмышның кулланылу үзенчәлекләре.

Алмашлыклар. Тартым алмашлыклары, аларның мәгънәләре. Тартым алмашлыкларын сөйләмдә дөрес куллану. Күрсәтү алмашлыклары. Рус телендә бу алмашлыкларның мәгънәләрен белдерү юллары.

Фигыль. Боерык фигыльләр. Аларның мәгънәләре, зат-сан белән төрләнеше. Боерык фигыльләрне тексттан табу, аларны сөйләмдә тиешле интонация белән куллану.

Үткән һәм киләчәк заман хикәя фигыльләр. Аларның зат-сан белән төрләнеше.

Хикәя фигыльләрнең барлык заман формаларын зат-сан белән төрләндерү, аларны сөйләмдә дөрес куллану.

Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр. Аларны сөйләмдә дөрес куллану.

Кабатлау.

## 3. Синтаксис - 5 сәгать

Татар һәм рус телләрендә сүзтезмә һәм җөмлә, аларда сүзләрнең урнашу тәртибе.

Җөмләнең баш кисәкләре. Исемнәр һәм зат алмашлык-ларының җөмләдә ия булып килүе.

Боерык һәм хикәя фигыльләрнең җөмләдә хәбәр булып килүе.

Җыйнак һәм җәенке җөмләләр.

Җөмләнең иярчен кисәкләре. Сыйфатларның, тәртип саннарының, исемне ачыклап, җөмләдә аергыч булып килүләре.

Җөмләнең тиңдәш кисәкләре, алар янында җыючы һәм каршы куючы теркәгечләрне дөрес куллану.

Эндәш сүзләр. Алар янында тыныш билгеләрен дөрес кую. Эндәш сүзләрне тиешле интонация белән әйтү.

*Ел буена үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау.*

## 4. Бәйләнешле сөйләм үстерү - 4 сәгать

Өйрәнелгән сүз төркемнәренең тиешле формаларын кулланып, сүзтезмәләр һәм җөмләләрне телдән яки язып төзү. Диалогларда аларны дөрес куллану.

Укылган өзек яки караган рәсем буенча, өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя төзү.

Тиңдәш кисәкләрне сөйләмдә дөрес куллану.

Укылган өзек буенча «телдән рәсем ясау». Синоним, омоним, антоним сүзләрне урынлы куллану.

Төрле диктантлар язу.

Ел дәвамында терәк сүзләр белән яки алардан башка инша язу күнекмәләре тәрбияләү.

**Сөйләм үстерү өчен темалар**

Казанга — мең ел.

Яраткан китабым.

Яраткан язучым.

Мәктәп китапханәсендә.

Татарстан — безнең Ватаныбыз.

Яраткан фәнем.

Кышкы каникулда.

Милли киемнәребез.

Авылда яз.

Ашханәдә.

Театрда.

Әгәр укытучы булсам...

## IV сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр

IV сыйныф ахырында укучыларда төрле типтагы сүзлекләр белән эшләү күнекмәләре булдыру, аларның сүзлек байлыгын арттыру.

Сүзләрнең тамырын, кушымчаларын һәм нигезен табу. Төрле сүз төркемнәрен (исем, сыйфат, фигыльләрне) ясаучы кушымчаларны күрсәтү.

Мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларны билгеләү. Укытучы тәкъдим иткән сүзләрнең төзелешен тикшерә белү.

Исемнәрне килеш һәм тартым белән төрләндерү. Исемнәргә морфологик анализ ясау күнекмәләре булдыру (уртаклык яки ялгызлык булуын, берлектә яки күплектә килүен, килешен, тартым белән төрләнүе-төрләнмәвен, нинди җөмлә кисәге булып килүен күрсәтү).

Сыйфатларның төрле дәрәҗә формаларын ясау (гади, чагыштыру, артыклык һәм кимлек). Дәреслектә һәм укытучы тарафыннан бирелгән сыйфатларның төрле дәрәҗә формаларын ясап, алар белән җөмләләр төзү.

Микъдар һәм тәртип саннарын билгеләү, аларны сөйләмдә дөрес куллану.

Тартым алмашлыкларын телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану.

Боерык фигыльләрне зат-сан белән төрләндерү, хикәя фигыльләрнең барлык заманнарын зат-сан белән төрләндереп, аларны телдән сөйләмдә, инша һәм сочинение язганда дөрес куллану.

Җөмләнең баш кисәкләрен табып, аларның нинди сүз төркеме белән (иянең исем яки зат алмашлыгы, хәбәрнең хикәя яки боерык фигыль, тартым алмашлыгы белән) белдерелүеңә мисаллар әйтү, укытучы күрсәткән (яки

мөстәкыйль рәвештә укучы үзе тапкан) әдәби тексттан баш кисәкләрне күрсәтү.

Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану.

Җөмләнең иярчен кисәкләреннән аергычның сыйфат, сан белән белдерелүен күрсәтү. Тиңдәш кисәкләрне билгеләү, алар янында җыючы һәм каршы куючы теркәгечләрне куллану. Җөмләгә синтаксик анализ ясау күнекмәләре булдыру (ия, хәбәр, аергыч, тиңдәш кисәкләрне күрсәтә алу).

Эндәш сүзләрне иядән аеру, алар янында тыныш билгеләрен дөрес кую.

**Контроль эшләр графигы**

| **№ диктантлар** | **Контроль эшнең темасы** | **Якынча үткәрелергә тиешле дата** |
|---|---|---|
| 1 кереш | | 1.10 |
| 2 I чирек | “Авазлар һәм хәрефләр” бүлеге буенча | 29.10 |
| 3 II чирек | “Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан юлга күчерү “ темасы бунча | 24.12 |
| 4 II чирек | “Сүз төркемнәре “ темасы бунча | 18.03 |
| 5 IV чирек | 2018-2019 нчы уку елы өчен 2 сыйныф курсы буенча йомгаклау контроль эше. | 20.05 |